Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлегенең Яңа Чишмә авылы торак пунктында 2023 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2022 елның 16 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Яңа Чишмә авылының гражданнар җыены

КАРАР ИТӘ:

1. «2023 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Яңа Чишмә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, 85 яшьтән өлкәнрәкләр, өлкәннәр өчен интернат-йортта яшәүче гражданнардан һәм Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган әлеге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Яңа Чишмә авылының Чернышевский, Шмидт, Яшьләр, Бакча, Тирәкле, Мәктәп, Октябрь, Тихонов, 2 нче Яр буе, Горький, Попов урамнарында контейнер мәйданчыкларын төзү һәм реконструкцияләү (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Төзүчеләр урамында тротуар төзү (материаллар сатып алу, вак таш, асфальт, бордюрлар салу, килешү буенча эшләр өчен түләү)

3. Әлеге карарны Яңа Чишмә авыл җирлегенең Яңа Чишмә авылы мәгълүмат стендларында, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә
авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе

Т. Н. Маланчева